| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 9 декабрь № 930

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмаларның «Invest in Tatarstan» имидж кампаниясен тормышка ашыруда катнашуга бәйле чыгымнарын каплау өчен субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 22 декабрь, 1116 нче карары белән расланган Оешмаларның «Invest in Tatarstan» имидж кампаниясен тормышка ашыруда катнашуга бәйле чыгымнарын каплау өчен субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының « Оешмаларның «Invest in Tatarstan» имидж кампаниясен тормышка ашыруда катнашуга бәйле чыгымнарын каплау өчен субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 22 декабрь, 1116 нче карары белән расланган Оешмаларның «Invest in Tatarstan» имидж кампаниясен тормышка ашыруда катнашуга бәйле чыгымнарын каплау өчен субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 нче пунктның бишенче абзацына «(дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш)» сүзләрен өстәргә;

8 нче пунктка «, шулай ук Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасының дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан оешманың субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрүгә оешманың ризалыгы карала» сүзләрен өстәргә;

9 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Чит ил массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасының инвестицияләр җәлеп ителеше турында мәгълүмати материаллар урнаштыру эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар, субсидияне алу өчен, Вәкаләтле органга түбәндәге документларны кертә:

Вәкаләтле орган раслаган форма буенча субсидияләр бирүгә заявка;

оешманың соңгы хисап көненә салымнар һәм җыелган акчалар буенча бурычлары булмау турында салым органыннан белешмә (агымдагы хисап чорында теркәлгән оешмалардан тыш);

оешманың соңгы хисап көненә хуҗалык эшчәнлегенең хисап чорлары өчен бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы күчермәсе (агымдагы хисап чорында теркәлгән оешмалардан тыш);

гамәлгә кую документлары күчермәләре;

чит ил массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасының инвестицияләр җәлеп ителеше турында мәгълүмати материаллар урнаштыру буенча төзелгән шартнамәләрнең, шартнамәләр буенча түләүне раслаучы, банк билгеләп куйган түләү йөкләмәләренең һәм башкарылган эшләр (күрсәтелгән хезмәтләр) актларының күчермәләре.»;

түбәндәге эчтәлекле $9^1$ нче пункт өстәргә:

«$9^1$. Гариза бирүче үз инициативасы буенча түбәндәге документларны кертергә хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында шаһәдатнамә;

салым органында исәпкә кую турында шаһәдатнамә;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

Гариза бирүче алда әйтелгән документларны кертмәгән очракта, Вәкаләтле орган әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.»;

14 нче пунктта «оешманың әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне бозу фактлары ачыкланган» сүзләрен «аларны керткәндә билгеләнгән шартларны бозган»;

түбәндәге эчтәлекле 15 нче һәм 16 нчы пунктлар өстәргә:

«15. Субсидияләр бирү турында шартнамәдә каралган очракларда хисап финанс елында файдаланылмаган субсидияләрнең калган өлеше оешма тарафыннан хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтарылырга тиеш.

16. Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы оешманың субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә законнар белән билгеләнгән тәртиптә тикшерү үткәрә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\930.docx